КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 2 март г.Казань № 151

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 935 нче карары белән расланган Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 935 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1339 нчы; 2023 ел, 11 ноябрь, 1464 нче; 2023 ел, 8 декабрь, 1582 нче; 2024 ел, 23 октябрь, 909 нчы; 2024 ел, 30 декабрь, 1281 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Министрлык исеменнән контроль (күзәтчелек) чараларын түбәндәге вазыйфаи затлар (алга таба – вәкаләтле хезмәткәрләр) башкарырга хокуклы:

министр;

министр урынбасары;

Транспорт идарәсе башлыгы;

Автомобиль юллары идарәсе башлыгы;

Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлеге башлыгы (алга таба – Транспорт бүлеге);

автомобиль юллары бүлеге башлыгы;

Транспорт бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

Транспорт бүлегенең әйдәүче консультанты;

Автомобиль юллары идарәсенең юл хәрәкәте иминлеге һәм контроль-күзәтчелек эшчәнлеге секторы мөдире (алга таба – ЮХИ секторы);

ЮХИ секторының әйдәүче консультанты.»;

3.2 пунктның беренче абзацында татар текстында «Контроль объектлары» сүзләрен «Юл хуҗалыгы өлкәсендә контроль объектлары һәм юл сервисының эксплуатацияләнә торган объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктның таблицасыннан соң беренче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Транспорт өлкәсендә шактый урта, уртача риск категорияләренә кертелгән контроль объектларына карата контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль кысаларында мәҗбүри профилактик визитлар үткәрү ешлыгы турында» 2025 елның 1 октябрендәге 1511 номерлы карары (алга таба – 1511 номерлы карар) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Транспорт өлкәсендә түбән риск категориясенә кертелгән контроль объектларына карата тикшерүләр үткәрелми.»;

3.8 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«югары риск категориясе өчен – ике елга бер планлы контроль (күзәтчелек) чарасы яисә елга бер мәҗбүри профилактик визит;

урта риск категориясе өчен – 1511 нче карар нигезендә;»;

3.9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Риск категорияләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүне (функцияләр башкаруны) тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системалары турында» 2011 елның 24 октябрендәге 861 номерлы карары нигезендә Федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге), төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төрләре бердәм реестрына белешмәләр кертү юлы белән бирелә.»;

3.10 пунктның алтынчы һәм җиденче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

3.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Контрольдә тотылучы зат Министрлыкка, шул исәптән «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын файдаланып, башка риск категориясенә кертү өчен риск категориясенә туры килгән очракта, үзе башкара торган эшчәнлек рискы категориясе яисә аңа караган (аның тарафыннан файдаланыла торган) башка контроль

объектлары рискы үзгәрү турында гариза бирергә хокуклы.»;

3.12 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза Министрлыкта бер эш көне эчендә теркәлә.»;

3.14 пунктта «боерык формасында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.16 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Кисәтүгә карата каршы килүләр контрольдә тотылучы зат тарафыннан Министрлыкка кәгазь рәвештә почта аша яки кисәтүдә күрсәтелгән Министрлыкның электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яисә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрелә.

Кисәтүгә карата каршы килүләр Министрлыкта бер эш көне эчендә теркәлә.»;

4.10 пунктта «каршы килүләр алынган көннән 20 эш көне» сүзләрен «аны теркәгән көннән 10 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

4.14 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) шәхси мөрәҗәгать иткәндә – телефон элемтәсе, электрон почта, видео-конференц-элемтә яки «Инспектор» мобиль кушымтасы аша;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Контрольдә тотылучы зат, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (функцияләр)» федераль дәүләт мәгълүмат системасын файдаланып, консультация бирүне гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать җибәрергә хокуклы. Мондый мөрәҗәгать бер эш көне эчендә теркәлергә һәм Министрлык тарафыннан аны теркәгән көннән алып 10 эш көне эчендә каралырга тиеш.»;

4.15 пунктта «видео-конференц-элемтә» сүзләреннән соң «яки «Инспектор» мобиль кушымтасы» сүзләрен өстәргә;

4.20 – 4.24 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.20. Профилактик визит контрольдә тотылучы зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видеоконференция элемтәсен яки «Инспектор» мобиль кушымтасын файдалану юлы белән уздырыла. Профилактик визит контроль (күзәтчелек) органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яисә контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча уздырыла.

4.21. Мәҗбүри профилактик визит түбәндәгечә үткәрелә:

1) югары риск категориясенә кертелгән контрольдә тотылучы затларга карата елга бер мәҗбүри профилактик визит, ә шактый, урта яки уртача риск категорияләренә кертелгән контрольдә тотылучы затларга карата әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында билгеләнгән үткәрү ешлыгына карап;

2) түбәндәгеләр йөкләмәсе буенча:

Россия Федерациясе Президенты;

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары – Россия Федерациясе Хөкүмәте Аппараты Җитәкчесе белән килештерелгән Россия Федерациясе Хөкүмәте

Рәисе яки Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары;

Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе).

Контрольдә тотылучы затларга карата мәҗбүри профилактик визитлар шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән башка очракларда да үткәрелә.

4.22. Мәҗбүри профилактик визит кысаларында вәкаләтле хезмәткәр кирәк булганда тикшерү, кирәкле документларны таләп итү, үрнәкләр (өлгеләр) сайлап алу, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза үткәрергә мөмкин.

Мәҗбүри профилактик визитта контрольдә тотылучы зат тарафыннан аны үткәрүдән баш тарту күздә тотылмый.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында контрольдә тотылучы затка 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә аны үткәрә башлаганга кадәр 24 сәгатьтән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү срогы 10 эш көненнән артып китә алмый һәм экспертиза, сынаулар уздыру өчен кирәкле срокка озайтылырга мөмкин.

4.23. Мәҗбүри профилактик визит булганда, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә, әгәр мондый бозулар 248-ФЗ номерлы Федераль законның $90^1$ статьясында каралган тәртиптә мәҗбүри профилактик визит үткәрү тәмамланганга кадәр бетерелмәгән булса, контрольдә тотылучы затка бирелә.

4.24. Контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча профилактик визит 248-ФЗ номерлы Федераль законның $52^2$ статьясы нигезендә үткәрелә.»;

5.3 пунктта «1, 3 – 6 пунктларында» сүзләрен «1, 3 – 5, 7, 9 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

5.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инспекция визиты, күчмә тикшерү дистанцион үзара хезмәттәшлек чараларыннан, шул исәптән видеоконференция элемтәсе аша, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә мөмкин.»;

5.21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.21. Планнан тыш документларны тикшерү бары прокуратура органнары белән килештереп (248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4 пунктлары нигезендә аны үткәрү очрагыннан тыш) башкарылырга мөмкин.»;

5.23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.23. Күчмә тикшерү оешманың (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структура бүлекчәләренең) урнашу (эшчәнлек гамәлгә ашыру) урыны, гражданның эшчәнлек гамәлгә ашыру урыны, контроль объектының урнашу урыны буенча үткәрелергә мөмкин, шул ук вакытта контролдә тотылучы зат белән үзара бәйләнешкә керү рөхсәт ителми.

Күчмә тикшерү барышында вәкаләтле хезмәткәр һәркем файдалана алган (чикләнмәгән затлар төркеме булу өчен ачык) җитештерү объектларын карарга хокуклы.

Күчмә тикшерү 248-ФЗ номерлы Федераль законның 75 статьясы нигезендә үткәрелә.»;

5.24 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

5.25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.25. Күчмә тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.»;

5.27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.27. Планнан тыш күчмә тикшерү бары прокуратура органнары белән килеш-тереп (248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4 пунктлары, 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә аны үткәрү очракларыннан тыш) үткәрелергә мөмкин.»;

5.32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.32. Карау инспектор тарафыннан контрольдә тотылучы зат яки аның вәкиле катнашында (күчмә тикшерү үткәрүдән тыш) һәм (яки) фотога төшереп яки видеога яздырып гамәлгә ашырыла.»;

5.56 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) контроль (күзәтчелек) чарасы акты рәсмиләштерелгәннән соң, контрольдә тотылучы затка ачыкланган мәҗбүри таләпләр бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирергә, аларны бетерү өчен нигезле срокларны күрсәтергә;

5.61 пунктта татар текстында «Министрлыкның вәкаләтле хезмәткәре» сүзләреннән соң «контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү мөмкин түгеллеге турында акт төзелгән датадан алып өч айдан да соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

VI бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VI. Министрлык карарларына, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү

6.1. Карарлар кабул ителгән яки гамәлләр кылынган (гамәл кылынмаган) контрольдә тотылучы зат, 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә таянып, Министрлык карарларына, аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирергә хокуклы.

6.2. Министрлык карарларына, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата суд аша шикаять бирү аларга суд аша шикаять биргәннән соң гына мөмкин.

6.3. Судка кадәр тәртиптә шикаять бирү 248-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.4. Министрлык карарына, аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять министр (министр урынбасары) тарафыннан карап тикшерелә.

6.5. Министр (министр урынбасары) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять Министрлыкның вазыйфаи затлары (кимендә өч вазыйфаи зат) арасыннан шикаятьләрне карап тикшерү өчен күмәк орган тарафыннан карап тикшерелә.

Шикаятьләрне карап тикшерү өчен күмәк орган булдыру турында карар министр тарафыннан кабул ителә.

6.6. Шикаять судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасында теркәлгән

көннән алып 15 эш көне эчендә, контроль объектларын тиешле риск категориясенә кертү турында карарга карата шикаять биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү 248-ФЗ номерлы Федераль законның 42, 43 статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Даими йөртүләр өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторы – ачык чыганакларда һәм массакүләм мәгълүмат чараларында квартал эчендә контрольдә тотылучы зат тарафыннан даими йөртүләр өлкәсендә расписание нигезендә башкарылмаган рейслар санына бәйле хезмәтләр тиешенчә күрсәтелмәү, транспорт чарасында пассажирлар, шул исәптән инвалидлар арасыннан пассажирлар йөртү өчен билгеләнгән җиһазның төзек эшләвен тәэмин ителмәү турында 15 һәм аннан күбрәк тискәре бәяләмә урнаштыру.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин